| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НИЖНЕЧЕКУРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТҮБӘН ЧӘКЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Нижнее Чекурское

2020нче елның 13нче ноябере №3/4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 апрелендәге 28/1 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен, даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга акчалата бүләкләүләр билгеләү турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, жирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләүләре күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары, Чүпрәле муниципаль районының Түбән Чәке авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 апрелендәге 28/1 номерлы (2018 елның 23 маендагы 30/1; 2018 елның 11 сентябрендәге 36/2; 2018 елның 01 декабрендәге 44/1; 2019 елның 14 гыйнварендәге 46/2 номерлы карарлары редакциясендә) «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен, даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга акчалата бүләкләүләр билгеләү турында » гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) "Авыл җирлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга хезмәт хакы күләме һәм шартлары" 1 нче кушымта таблицасын «

| Вазыйфаның атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 8 группа | 10 группа | 11 группа | 12 группа |
| Авыл җирлеге башлыгы | - | - | - | 15 300 |

түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

| Вазыйфаның атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 8 группа | 10 группа | 11 группа | 12 группа |
| Авыл җирлеге башлыгы | - | - | - | 15 759»; |

2) «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең вазыйфаи оклады күләме " 2 нче кушымта таблицасын «

| | Вазыйфаның атамасы | Вазифалы оклад | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 10 группа | 11 группа | 12 группа |
| 1. | Башкарма комитет сәркатибе | - | - | 14 847 |

түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

| | Вазыйфаның атамасы | Вазифалы оклад | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 10 группа | 11 группа | 12 группа |
| 1. | Башкарма комитет сәркатибе | - | - | 15292". |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Түбән Чәке авыл җирлеге башлыгы
Чүпрәле муниципаль районы
Татарстан Республикасы О.Б.Албутов